МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.11.2022 **г. Казань** № 2986

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 19.08.2022 ел, № 2261 боерыгы белән расланган Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында б о е р а м: Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 19.08.2022 ел, № 2261 боерыгы белән расланган Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

Министр М.Н.Садыков

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы белән
«14» 11 2022 № 2986

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 19.08.2022 ел, № 2261 боерыгы белән расланган Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Бүлек 1дә:

пункт 1.3. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә профильләштерү (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә, мөрәҗәгать итүченең хезмәт күрсәтүче орган үткәрә торган анкеталау нәтиҗәсендә билгеләнгән тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) үткәрелми.»;

бүлек 2дә:

пункт 2.3.2 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.2 Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе реестр язмасы булып тормый.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.»;

пункт 2.6.2 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча алынучы мәгълүматлар:

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында оешма булмауны раслый ( Монополиягә каршы федераль хезмәттән);

мөрәҗәгать итүче турында гариза бирүче тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләр буенча социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестрына айның беренче числосына язма кертү турында, анда мөрәҗәгать итүче документлар тапшыра

(Россия Федерациясе Юстиция министрлыгыннан).»;

беренче абзац пункт 2.6.3 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имза белән таныкланган электрон документлар рәвешендә, Бердәм портал, Республика порталы аша гариза биргәндә яисә КФҮдә кәгазь формасында күрсәтергә хокуклы.»;

бүлек 3тә:

пункт 3.3.2.1 түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Формалашкан гаризаны формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан гариза бирүченең гаризаның электрон формасын тутыру барышында Министрлык билгеләгән таләпләр нигезендә автоматик рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал

гаризаның дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны юкка чыгару тәртибе турында гаризаның электрон формасында турыдан туры мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.»;

беренче абзац пункт 3.3.3.2 үзкөчен югалткан дип танарга;

пункт 3.4 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Мәгълүмат алу, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1 Запрос җибәрү өчен нигез булып мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы тора.

3.4.2 Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) – Министрлык хезмәткәре (алга таба – ведомствоара запрослар юллау өчен җаваплы вазыйфаи зат). Ведомствоара запрослар юллау өчен җаваплы вазыйфаи зат әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында запрослар әзерли һәм юллый (шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып).

Ведомствоара мәгълүмати запрос күрсәтелгән органнарга мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага беркетелгән документларны теркәү көнендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып хакимият органнарына һәм (яисә) хакимият органнарына буйсынган оешмаларга җибәрелгән запрослар тора.

3.4.3 Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запросларга нигезләнеп сорала торган документларны (белешмәләрне) бирәләр яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яисә) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамә (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрәләр.

Ведомствоара запрослар буенча әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки булган мәгълүматлары) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлеген оештыруның тәкъдим ителгән кагыйдәләрен раслау турында, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә тиешле ведомствоара запрос җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмыйча әлеге документлар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре – ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр) яисә баш тарту турында хәбәр.

3.4.4 Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазьдә башкарылырга

мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада тормышка ашыра алмаганда;

2) ведомствоара запрос җибәргәндә кәгазьдә оригиналь документларны тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазьдә гамәлгә ашырылса, регламентның 2.6.2 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки мәгълүматлары) әлеге документлар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

Федераль закон № 210-ФЗ 72 статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара запросларга җавап әзерләү һәм җавап җибәрү срогы ведомствоара запрос кергән көннән биш эш көненнән артып китә алмый.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

Административ процедураның нәтиҗәсе - ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы мәгълүматларны) алу яки баш тарту турында хәбәрнамәне алу.»;

бүлек 5тә:

пункт 5.1 түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«КФҮ хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге КФҮ җитәкчесенә җибәрелә.

КФҮнең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮнең гамәлгә куючысына (алга таба – КФҮнең гамәлгә куючысы) җибәрелә.»;

пункт 5.3 түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» челтәрен, КФҮнең рәсми сайтын, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталын (https://www.gosuslugi.ru) кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.».